«Татарстан Республикасы  Зеленодольск муниципаль районының
7 нче гомуми урта белем мәктәбе» муниципаль бюджет  гомумбелем
учреждениесе

Каюм Насыйри эзләре суынма

(Олы Ачасыр авылы буенча виртуаль сәяхәт)

Укытучы : Хәмидрва З.З

Башкарды:7нче сыйныф укучысы Вәлиуллина Алия

2020 ел

Эчтәлек

1. Кереш.

2. Виртуаль сәяхәтнең маршруты.

3. Олы Ачасыр авылының тарихы, килеп чыгышы.

4. Авыл буйлап виртуал сәяхәт- микротопонимиясе.

5. Йомгаклау.

**6.** Файдаланылган әдәбият.

7. Кушымта.

## Кереш

Күренекле галим, укытучы-педагог, мәгърифәтче һәм әдип Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров(Каюм Насыйри) -1825 елның искечә 14 (27) февралендә, элекке Казан губернасы, Зөя өязе (хәзерге Татарстан республикасы, ЯшелҮзән районы), Югары Шырдан авылында туа. К. Насыйри гомерен, бөтенләй дип әйтерлек, Казанда яшәп, иҗат өстендә уздыра. Сәяхәтләреннән тыш, һәр язны дип әйтерлек, туган авылы Югары Шырданга кайта торган була. Шунда Зөя һәм Тау ягындагы авылларга чыгып, андагы тарихи истәлекләрне-һәйкәлләрне тикшереп-карап йөрергә яраткан. Ул бик күп иске кабер ташлардагы язмаларны җентекләп укыган, халыкның үз авызыннан җырлар һәм фольклор материалларын җыйган.

Олы Ачасыр авылына виртуаль сәяхәт эшләгәндә, авылның тарихы, микротопонимиясе, турында мәгълүматлар туплаганда, Каюм Насыйри хезмәтләреннән файдаландым. Ул Казан тарихы белән берлектә, күп кенә татар авылларының (Югары Шырдан, Мамадыш, Бакырчы, Олы Ачасыр һ.б) тарихын, халкының телен, гореф – гадәтләрен, сүз сәнгатен, фольклорын, таулар, елгаларының килеп чыгышын өйрәнә, мәкаләләр яза. Чынлап караганда, Каюм Насыйри төрле төбәкләрнең ономастикасын өйрәнгән. Ономастика-тел белеменең барлык төр ялгызлык исемнәрен өйрәнә торган махсус тармагы. Хәзерге вакытта ономастика фәне үзе дә дөньякүләм игътибарга лаек.

Каюм бабаның эшчәнлеге – милләткә фидакярләрчә хезмәт итүнең

бөек бер үрнәге. Аның хезмәтләре – хәзерге милли тормышыбыз өчен дә аваздаш булган бай хәзинә. Иҗат мирасы, еллар узган саен, кыйммәтен арттыра бара. Без шундый галимебез булуы белән горурланабыз.

Мин үземнең фәнни эшемне Каюм Насыйри белән бәйле булган Олы Ачасыр авылы турында язарга булдым. Олы Ачасыр авылының тарихы, килеп чыгышы белән кызыксындым, авылның тарихына бәйле кызыклы мәгълүматлар белән таныштым. Кайбер кешеләре белән очрашып сөйләштем, авыл буйлап виртуаль сәяхәтнең юнәлешен билгеләгәндә, Каюм Насыйри эзләреннән барган кебек рухландым.

**Виртуаль сәяхәтнең маршруты**

-Авыл буйлап сәяхәт-тарихы, микротопонимиясе;

- 1997нче елның 1нче мартында төзелгән Каюм Насыйри исемендәге орхеологик – тарих һәм этнография музеенда;
- Олы Ачасыр тулы гомуми урта белем мәктәбендә;
- динебезне, гореф-гадәтләрне, йолаларыбызны саклап калуда зур роль уйнаган мәчеттә;
- авылның иң матур җиренә урнашкан, тирә – якка ел саен үткәрелә торган бәйрәмнәре белән танылган Бәйрәш(Лилия) чишмәсендә булу, суын татып карау;
- сабантуй, каз өмәләре үткәрелә торган урыннарда
- Яшел Үзәнгә кайту

**Олы Ачасыр авылының тарихы, килеп чыгышы**

Олы Ачасыр авылы үзенең тарихы, килеп чыгышы белән кызыклы. Ачасыр авылы Яшел Үзән районының Идел аръягында урнашкан иң зур авылларның берсе булып тора. Анда хәзер 400 гә якын йорт бар. 1000 нән артык кеше яши. Ә элек авыл шактый зур булган. Мәскәү архивында саклаучы борынгы язмаларда авылның 1771 елгы язмаларда искә алынуы турында әйтелә. Ул чакта анда 530 йорт һәм 3000 кеше булган. Тагын бер

кызык сан, авылда колхоз номеры булып, бу сан 790 га җитә торган булган. Колхозга ничәнче кеше булып кергәнне исәпләп барганнар.

Олы Ачасыр авылы - бик борынгы авыл. Авылының борынгы заманнарда барлыкка килүе галимнәр тикшерүләрендә, якташыбыз мәшһүр Каюм Насыйри хезмәтләрендә, профессор Г.Саттаров һәм академик М. Зәкиев эзләнүләрендә раслана. Соңгы тарихи язмаларда безгә Олы Ачасыр авылына Идел Болгары тар-мар ителгәннән соң **XII** - XIII гасырларда болгардан күчеп килүчеләр тарафыннан нигез салынган дип фараз кылырга ирек бирә Академик М.Зәкиевның соңгы вакыттагы фикерләрен раслый. Бәлки Ачасыр да болгарлар килгәнче дә буш җир булмагандыр, анда бәлки һуннар нәселе дә сугылгандыр. М.З.Зәкиев, Я.Ф. Кузьмин - Юманди (Казан, 1993 "Волжские Булгары и их предки" китабы) борынгы, "писцовые книги"дан Ачасыр турында кызык мәгълүматлар китерәләр. Безнең көннәргә кадәр халыкта Ачасырның нигезе чуваштан дигән фикер дә яшәп килә..

Авылның исеме дә сәер. Ачасыр русчага тәрҗемә ителми. Күршедәге чувашлар хәзерге заман чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә Ачасыр "баласыз" яки "атасыз" сүзен аңлата диләр. Моннан 100 елдан артык Каюм Насыйри әйткән "атасыз" мәгънәсе дә безнең көннәрдә профессор Г.Саттаров әйткән "баласыз" мәгънәсе дә дөрес булып чыгалар. Каюм Насыйри үзенең "Материалы по археологии и этнографии по селам Свияжского уезда" исемле китабында беренче Олы Ачасыр кешесе турында мондый легенда язып калдырган: "Бу Ачасыр авылына иң әүвәл килеп утырган кешенең исеме, кем икәне мәгълүм түгел. Әмма риваятьләр изаһлык бирәдер, анда әүвәл бер ятим бала белән бер чуваш хатыны килеп утырган. Ул вакытта Ачасыр урыны урман булган. Ул кеше шул ятим бала белән килеп, баласын бишеге белән имән ботагына асып, үз теленчә: "Йокла, атасыз, йокла!" - дип тибрәткән. Шуннан Ачасыр дип исем калгандыр. "Ачасыр" дигәне чуваш сүзе булырга кирәк. "

**Авыл буйлап виртуаль сәяхәт- микротопонимиясе**

Авылның микротопонимиясе гаҗәп үзенчәлекле икән. Олы Ачасыр

авылының урнашуы да бик борынгы. Ул чокыр яисә андагы елга буенда урнашкан. Без тар урамнар, кәкре һәм көтелмәгән борылышлары булган тыкрыклардан барабыз. Халык телендә йөргән Май тавы урамы юлы Май тавына илтә. Як-якка карыйм нинди матурлык! Авылның тирә-ягын зур булмаган урманнар әйләндереп алган һәм алар һәркемне сокландыра. Исемнәренә килгәндә, Бүре куагы, Шырдан, Рус урманы исемлеләре бар.

Ачасыр кырларын кипмәүче Сәкел елгасы кисеп үтә. Аның шактый тирән һәм киң яр буйларында шулай ук сәер исемле чокырлар күп. Сәкел елгасының исемен чуваш теле белән аңлатырга мөмкин. Сәкел - кайберәүләр юлда тоткарлык мәгънәсендә диләр, кайберәүләр Сәкел - сак ил дип аңлатмакчы була. Сәкел башыннан ерак түгел бер калкулык бар. Ул калкулыктан хәзер Казан утлары күренә. Якты булганга без күрә алмадык. Имеш борынгы заманда анда илне саклаганнар. Дошман килеп чыкса, ут ягып Казанга хәбәр салганнар. Бу мәрхүм Кәрим абый Гыйсмәтуллин сөйләгән легенда.

Аннан соң Буа елгасыннан авылга таба чокыр бар. Хәзер дә Кирәмәт тавында адашу очраклары бар, "изгеләр" адаштыра диләр. Авыл исеме кебек чокырларның исемнәре дә нindидер дәрәҗәдә үткәннең серләренә төшенергә ярдәм итәләр. Авылда янында бик биек булмаган таулар да бар. Май тавы, Әкә тавы, Олы инеш, Кече Алан әнә шундыйлардан. Олы Ачасырдан төп юллар Май тавы күпере аша Казанга, Зөягә, Яшел Үзәнгә юнәлә.

**Киләсе барасы урыныбыз К.Насыйри исемендәге Архитектура-этнография комплексы.** Бу музей үзендә бөек мәгърифәтче Каюм Насыйриның рухын саклый, шуңа да анда килгән кешеләр җан тынычлыгы алып, канатланып, рухланып чыгалар. Миндә музей зур кызыксыну уятты, һәр экспонатны тотып, фотога алып, әбиләре сөйләгән хатирәләрне искә төшереп хисләнеп йөрдем.

Каюм Насыйриның Югары Шырдан авылындагы йортын 1947 нче елны Олы Ачасыр кешесе Гани бабай сатып ала да, күчереп сала. Үләр алдыннан ул бу йортта музей ясарга дип әманәт әйтеп калдыра. 1997нче

елның 1 мартында Олы Ачасыр авылында аның исемендәге археология-тарих һәм этнография музее ачыла.

Динебезне, гореф гадәтләрне, йолаларыбызны саклап калуда зур роль уйнаучы **мәчеткә килеп җиттек.** Ачасыр авылы гомер-гомергә үзенең динлелеге, кайчандыр хәтта ике мәчетле булуы белән тирә-күрше авыллардан аерылып тора. Бүген дә авылда зур, матур мәчет эшләп килә. Мәчеттә хаҗи Габбаз хәзрәт тарафыннан "Якшәмбе" мәктәбе дә эшли. Шушы мәктәпнең эшчәнлеген күрергә дип  авылның иман йорты – мәчет эченә кердек. Анда шәкертләр, картлар белән дини темаларга түгәрәк өстәл оештырыла.

**Ачасыр тулы гомуми урта белем мәктәбе үзенең эшчәнлеге белән аерылып тора.** Татар мәктәбендә белем алучы укучыларда милли үзаң тәрбияләү, татар телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклау өстендә күп эшлиләр дигән нәтиҗәгә килдем.

Олы Ачасыр авылын чишмәләр авылы дип атап йөртәләр, чөнки бу авыл чишмәләргә бик бай булган. Кайчандыр 16 чишмәсе белән дан тоткан авылның бүген 7 чишмәсе генә калган. Авыл тау башына салынган һәм аны эреле-ваклы чишмәләр әйләндереп алган. Аның нинди генә юк, Бәйрәш кебек тарихларга кереп калган, үткән гасырлардан алып хәзергә кадәр агып ятучы көчле мул сулысы да, һәм самавыр борыныннан агып чыккан кебек челтер-челтер агып ятучы Тукый чишмәләре авылыбызның табигать биргән бүләкләре. Тагын бер чишмә - Тимер улак. Суы акрынрак. Шул урам кешеләре тарафыннан улак куелган. Җәе буе хатын-кыз жылы һәм көчле суда кер юа.

**Музейдан "Бәйрәш" чишмәсе буена юл тоттык**. "Бәйрәш" чишмәсе - бик күптәнге тарихи чишмә. Каюм Насыйри истәлекләрен караганда, Болгар дәүләте таралгач өч кеше килеп шушы урында чишмә казып карый. Көчле агымлы Бәйрәш чишмәсенең тарихы шул елларга барып тоташа.  Бәйрәш бабай - К. Насыйриның ерак бабасы. Урыны да тау астында бик матур урынга урнашкан. Юкка гына ел саен диярлек биредә чишмә, авыл бәйрәмнәре үткәрелми. Авылдан чыккан эшмәкәр Минуллин Әнвәр Габбаз

улы тарафыннан чишмә яңартылды, шуңа да ул тагын да матуррак һәм ямьлерәк булып китте.

Бу чишмәгә юл кыш көне дә, җәй көне дә өзелми. Чишмәгә бүләк итеп ак сөлгеләр-чүмечләр куелып тора. Гайнуллина Хәлимә әбинең улы Мансур, килене Луиза, оныгы Камил, Яшел Үзән шәһәрендә яшәсәләр дә, авылга бик еш кайтып, Бәйрәш-Лилия чишмәсенә суга барырга яраталар. Алар миңа үзләренең гаилә архивыннан, очрашу истәлеге итеп, Бәйрәш чишмәсе турында язылган видеоязма да бирделәр.

Аның саф суы җанга шифа бирә, тәннәрдәге бөтен арганлыкны бетерә. Чишмәнең шифалы суын эчкәч, сабантуй, каз өмәләре үткәрелә торган урыннарда булып, кайтыр юлга чыктык.

Вакыт инде төштән соңга авышса да аерыласы килмәде. Тагын да нидер сөйләшеп каласы, карыйсы, күреп өлгермәгән җирләр калды кебек.

## Йомгаклау

Сүземне тәмамлап шуны әйтәсем килә, авылның табигате белән горурланырлык. Кайсы якка гына карама, бөтен җир яшеллек белән күмелгән, мактанырлык урман-чишмәләре бар. Аларны югалтмыйча саклап калу һәр кешенең изге бурычы. Олы Ачасыр халкы күңелле яши. Ел саен язгы чәчү эшләре беткәч, татарларның күңелле бәйрәме-Сабантуй булып уза. Көзен каз өмәләре, Сөмбелә бәйрәмнәрен үткәрүне дә халык онытмый. Чишмә бәйрәмнәрен уздырып торалар. Олы Ачасыр эшмәкәре Әнвәр Миңнуллинны кем генә белми. Төрле бәйрәмнәр аның ярдәменнән башка узмый. Күренекле артистларны да чакырып авылдашларның күңелен күтәрә. Мәчетләрнең ачылуында да өлеше зур. ЯшелҮзән шәһәрендә дә кешеләре кайда гына, кем булып кына эшләми? Алар зыялы, туган авылларына тугрылыклы булулары белән аерылып торалар.

Олы Ачасыр авылы буйлап сәяхәт итү миңа күп нәрсәләр бирде. Әйе, мондый очрашулар, күрешүләр кирәк икән. Үзеңнең милләттәшләрең белән

аралашу горурлык хисе тудыра. Шушы очрашуны оештыручыларның барчасына да зур рәхмәтебезне җиткерәбез һәм мондый очрашулар соңгысы булмас әле дигән, теләктә калабы

**Файдаланылган әдәбият**

1. Каюм Насыйри. Әсәрләр. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1971ел.

2. Каюм Насыйри. Сайланма әсәрләр. Таткнигоиздат , 1956 ел.

3. Каюм Насыйри . Сайланма әсәрләр. 4 томда, 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003ел

4. Каюм Насыйри. "Материалы по археологии и этнографии по селам Свияжского уезда”. Казан. 1880ел.

4. Татар әдәбияты тарихы. 6 томда, 2 том. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985ел.

5. Х. Миңнегулов. Әдәбият, 9 класс. Казан, «Мәгариф» 1994ел.

6. М.З.Зәкиев, Я.Ф. Кузьмин - Юманди Казан, 1993 "Волжские Булгары и их предки".

7. Г.Ф. Саттаров.Татар исемнәре ни сөйли. Казан. Рәннур. 1998ел.



***Мәктәп яныннан төшергәндә Олы Ачасыр авылы.***



Олы Ачасыр авылында 1997нче елның 1нче мартында төзелгән Каюм Насыйри исемендәге орхеологитарих һәм этнография музее.

Сабантуй  монда була.



.





Олы Ачасырның мәчете (гаилә архивыннан).



Бүген дә авылда зур, матур мәчет эшләп килә. Мәчеттә “Якшәмбе” мәктәбе дә эшли.



**Бәйрәш -Лилия чишмәсе**



Аның саф суы җанга шифа бирә, тәннәрдәге бөтен арганлыкны бетерә.

**Олы Ачасыр авылы буенча виртуаль сәяхәт**

Бәхтиярова Эльвира Рәшит кызы ТРЗеленодол муниципаль районының7 нче гомуми урта белем мәктәбенең 11нче сыйныф укучысы, укытучы Хәмидова Зөлфирә Зәки кызы

Мин үземнең фәнни эшемне Каюм Насыйри белән бәйле булган Олы Ачасыр авылы турында язарга булдым. Каюм Насыйриның Югары Шырдан авылындагы йортын 1947 нче елны Олы Ачасыр кешесе Гани бабай сатып ала да, күчереп сала. Үләр алдыннан ул бу йортта музей ясарга дип әманәт әйтеп калдыра. 1997нче елның 1 мартында Олы Ачасыр авылында аның исемендәге археология-тарих һәм этнография музее ачыла

Олы Ачасыр авылы үзенең тарихы, килеп чыгышы белән кызыклы. Ачасыр авылы Яшел Үзән районының Идел аръягында урнашкан иң зур авылларның берсе булып тора. Анда хәзер 400 гә якын йорт бар. 1000 нән артык кеше яши. Олы Ачасыр авылының борынгы заманнарда барлыкка килүе галимнәр тикшерүләрендә, якташыбыз мәшһүр Каюм Насыйри хезмәтләрендә, профессор Г.Саттаров һәм академик М. Зәкиев эзләнүләрендә раслана. Авылның исеме дә сәер. Ачасыр русчага тәрҗемә ителми.Чуваш теленнән тәрҗемә иткәндә Ачасыр "баласыз" яки "атасыз" сүзен аңлата диләр. Моннан 100 елдан артык Каюм Насыйри әйткән "атасыз" мәгънәсе дә безнең көннәрдә профессор Г.Саттаров әйткән "баласыз" мәгънәсе дә дөрес булып чыгалар. Каюм Насыйри үзенең "Материалы

по археологии и этнографии по селам Свияжского уезда"  исемле китабында беренче Олы Ачасыр кешесе турында мондый легенда язып калдырган: "Бу Ачасыр авылына иң әүвәл килеп утырган кешенең исеме, кем икәне мәгълүм түгел. Әмма риваятьләр изаһлык бирәдер, анда әүвәл бер ятим бала белән бер чуваш  хатыны килеп утырган. Ул вакытта Ачасыр урыны урман булган. Ул кеше шул ятим бала белән килеп, баласын бишеге белән имән ботагына асып, үз теленчә: "Йокла, атасыз, йокла!" - дип тибрәткән. Шуннан Ачасыр дип исем калгандыр. ".

Ачасыр кырларын кипмәүче Сәкел елгасы кисеп үтә. Аның шактый тирән һәм киң яр буйларында шулай ук сәер исемле чокырлар күп, тирә-ягын зур булмаган урманнар әйләндереп алган. Исемнәренә килгәндә, Бүре куагы, Шырдан, Рус урманы исемлеләре бар. Сәкел елгасының исемен чуваш теле белән аңлатырга мөмкин. Сәкел - кайберәүләр юлда тоткарлык мәгънәсендә диләр, кайберәүләр Сәкел - сак ил дип аңлатмакчы була. Сәкел башыннан ерак түгел бер калкулык бар. Ул калкулыктан хәзер Казан утлары күренә. Имеш борынгы заманда анда илне саклаганнар. Дошман килеп чыкса, ут ягып Казанга хәбәр салганнар. Бу мәрхүм Кәрим абый Гыйсмәтуллин сөйләгән легенда. Буа елгасыннан авылга таба чокыр бар. Хәзер дә Кирәмәт тавында адашу очраклары бар, "изгеләр" адаштыра диләр. Авыл исеме кебек чокырларның исемнәре дә ниндидер дәрәҗәдә үткәннең серләренә төшенергә ярдәм итәләр. Авылда янында бик биек булмаган таулар да бар. Май тавы, Әкә тавы, Олы инеш, Кече Алан әнә шундыйлардан. Олы Ачасырдан төп юллар Май тавы күпере аша Казанга, Зөягә, Яшел Үзәнгә юнәлә.

Олы Ачасыр авылын чишмәләр авылы дип атап йөртәләр, чөнки бу авыл чишмәләргә бик бай булган. Кайчандыр 16 чишмәсе белән дан тоткан авылның бүген 7 чишмәсе генә калган. Авыл тау башына салынган һәм аны эреле-ваклы чишмәләр әйләндереп алган. Аның ниндие генә юк, Бәйрәш кебек тарихларга кереп калган, үткән гасырлардан алып хәзергә кадәр агып ятучы көчле мул сулысы да, һәм самавыр борыныннан агып чыккан кебек челтер-челтер агып ятучы Тукый чишмәләре авылның табигать биргән бүләкләре. Тагын бер чишмә - Тимер улак. Суы акрынрак. Шул урам кешеләре тарафыннан улак куелган. Җәе буе хатын-кыз жылы һәм көчле суда кер юа.

“Бәйрәш” чишмәсе - бик күптәнге тарихи чишмә. Каюм Насыйри истәлекләрен караганда, Болгар дәүләте таралгач өч кеше килеп шушы урында чишмә казып карый. Көчле агымлы Бәйрәш чишмәсенең тарихы шул елларга барып тоташа.  Бәйрәш бабай - К. Насыйриның ерак бабасы. Урыны да тау астында бик матур урынга урнашкан.

Олы Ачасыр халкы күңелле яши. Ел саен язгы чәчү эшләре беткәч, Сабантуй булып уза. Көзен  каз өмәләре, Сөмбелә бәйрәмнәрен  үткәрүне дә халык онытмый.